«23+8» бәйрәме

Максат: 1) укучыларны кыскача 23 нче февраль һәм 8 нче март бәйрәме тарихы белән таныштыру һәм аларны укучылар күңеленә илтеп җиткерү;

2) керәшен халкының җырларын һәм уеннарын өйрәнүне дәвам итү;

Җиһазлау: 1 парта, 23 нче февраль һәм 8 нче март открыткаларын ябыштырып ясау өчен открытка элементлары, клей, картон, чәчәкләр өчен 2 ваза, 14 аерым чәчәк , уен өчен курчак, 2 туп, татарча бию көе, уен өчен көй, “Токмач кисү” өчен 8 полоска ак кәгазь, токмач салу өчен 2 тәлинкә, 2 кайчы, мәкальләр,җырларга караоке, компьютер.

Бәйрәм барышы

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Килгән кунаклар ярымтүгәрәк ясап утыралар. Укучылар ярымтүгәрәк ян-ягына кызлар һәм малайлар командалары утыралар.

Бәйрәмне мәктәпнең җитәкчесе ачып җибәрә. Ул барлык килгән кунакларны, укытучыларны, укучыларны бәйрәмнәр белән котлый.

Алып баручы: Хәерле көн килгән кунаклар: әти-әниләр, әби-бабайлар, укытучылар,кызлар- малайлар.
Бүген бездә зур бәйрәм-
Бүген бездә күңелле.
Бүген күңелләр җырга
Һәм җилкенә биергә.

- Бүгенге бәйрәмебезне 23 нче февраль һәм 8 нче март бәйрәмнәренә багышларбыз. Менә инде 90 елдан артык безнең илебез 23 февраль бәйрәмен билгеләп үтә. Ә бәйрәмнең исеме берничә мәртәбә үзгәртелде.

1922 нче елда Кызыл Армия туган көн, 1923 нче елда Кызыл Армия көне, 1946 нчы елдан Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез флоты көне, 1995 нче елдан Ватанны саклаучылар көне исеме астында билгеләп үтелде.
Ә 2002 нче елдан 23 нче февраль Россиядә эш көне түгел, ә бәйрәм көн итеп билгеләп үтелә башлады. Бәйрәм ничек кенә аталса да без 23 нче февраль көнне ел саен безнең туган җиребезне

саклаган, саклый һәм киләчәктә саклаучы бабай-әтиләребезне, егет-энеләребезне,малайларыбызны бәйрәм белән котлыйбыз.
Сүзне, котлау өчен, Анжеликага бирәбез. Рәхим ит.
(Котлау укыла).
Алып баручы: 8 нче март –Халыкара хатын- кызлар көне. Бәйрәмнең тарихы 1857 нче елдан башлана. Ул вакытта Нью-Йорк тегүчеләре кечкенә хезмәт хакына канәгатьсезлек белдереп нәкъ менә 8 нче март көнне шәһәрдә масса күләм демонстрациягә чыгалар.
Әлеге көнне рәсми төстә бәйрәм итүгә исә Германия революционеры Клара Цеткин сәбәпче. Россиядә 8 нче март 1965 нче елдан рәсми төстә ял көне. Ә Үзбәкстанда 8 нче март әниләр көне булып санала. Әрмәнстанда мондый көн өчен 7 нче апрельне сайлаганнар.
8 нче март бәйрәмендә без барлык әби-әниләребезне, апай-сеңелләребезне, кызларыбызны котлыйбыз.
Котлау өчен сүзне Ромага бирәбез. Рәхим ит.
(Котлау укыла).
Алып баручы: Безнең укучыларыбыз, Сезне бәйрәм белән котлап, бүләкләр әзерләде. Шуны кабул итеп алыгыз. (Килгән кадерле кунакларга бүләкләр бирү).
Алып баручы: Туганнар да килгән безгә,
Дуслар да килгән безгә.
Дуслар, туганнар килгәчтен,
Тагын кем кирәк безгә.
Җырлыйк әле, җырлыйк әле
Унны да тугызны да.
Мәкнең алсу чәчәге күк
Күрәм барыгызны да.

- Ә хәзер “Җырлыйк, дуслар, бергәләп” җырын тыңлап үтик әле. Укучылар рәхим итегез. (Җыр башкарыла. Җырлап бетергәч укучылар ике командага аерылып басалар). Алып баручы:
  Малайлар һәм кызлар
  Сынашсын көчләрен.
  Кем көчле икәнен
  Күрербез шуннан без.
- Ә хәзер сүзне малайларга һәм кызларга бирәбез. Рәхим итегез.

Кызлар: Малайлар безнең батырлар
Һич кайчан сынатмыйлар.

Безнең мәктәп малайлары
Бар да бөркет кебекләр.

Малайлар: Безнең кызлар, уңган кызлар
Бар эшкә дә өлгерләр.
Безнең кызлар нурлы йөзле
Әйтерсең лә йолдызлар.

Алып баручы: Бәйрәм булгач открыткасыз булмый инде. Ә хәзер кызлар-малайларны открытка әзерләүдә сынап карыйбыз.

Ярыш “Открытка ясау”.

(Кызлар 23 нче февраль бәйрәменә, ә малайлар 8 нче март бәйрәменә открытка әзерлиләр. Һәр командадан берәрләп килеп открытканың бер элементын ябыштырып китәләр.)

Алып баручы: Молодцы! Рәхмәт. Урыннарга рәхим итегез. Менә нинди матур открыткалар килеп чыкты.)

Музыкаль пауза. “Солдатлар “ җыры. (Малайлар башкаруында.)

Алып баручы: Бәйрәм булгач чәчәксез, букетсыз булмый инде.
Ярыш “Чәчәк җыю”.

(Һәр команда үзенең вазасына (савытына) болыннан чәчәкләр.)

-Матур итеп тезелеп бастык. Һәр командадан берәрләп болынга барасыз, 1 чәчәк алып, үзегезнең вазагызга илтеп саласыз һәм ахырга барып басасыз.

(Вазаларда 1әр чәчәк, ә калган чәчәкләрне укучылар ташый.)

Алып баручы: Молодцы! Булдырдыгыз! Урыннарга рәхим итегез. Менә нинди матур букетлар килеп чыкты.

Ә хәзер барыбыз да ял итеп биеп алабыз.

(Күмәк бию)

Алып баручы: Рәхмәт. Тылсымлы, матур сүзләр әйткәч барыбызга да рәхәт була. Күңелләр күтәрелеп китә. Әйдәгез “Матур сүзләр” уенын уйнап алыйк әле.

Моның өчен әйләнә ясап утырабыз. Музыка башлануга курчак кулдан-кулга күчә. Музыка туктагач курчак кемнең кулында кала шул кеше

курчакка матур сүз әйтә. Музыка башлангач курчак әйләнә буенча йөрүен дәвам итә.

(Уйнау)

Алып баручы: Молодцы! Менә никадәр күп матур, тылсымлы сүзләр беләбез икән.

Музыкаль пауза. “Әниләр бәйрәме “ җыры. (Кызлар башкаруында.)

Алып баручы: Ә хәзер малайлар һәм кызларыбызның җитезлекләрен дә сынап карыйк әле.

Ярыш “Туры җибәр”. Һәр командадан беренче басып торучы бер-бер артлы баскан иптәшләренең аерып баскан аяклары арасыннан тупны артка тәгәрәтеп җибәрә. Соңгы кеше тупны ала һәм йөгереп алга килеп баса. Беренче кеше үз урынына килеп чыкканчы уен шулай дәвам итә.

(Ярышу)

Алып баручы: Молодцы! Бик җитез икән үзегез. Урыннарга рәхим итегез.

Музыкаль пауза. “Шофёр буласым килә “ җыры. (Кызлар башкаруында.)

(Җырлау)

Алып баручы: Бәйрәмнәр безнең табынсыз булмый ул. Ярыш “Табын ашлары”. Һәр командадан чират буенча берәр ризык , аш-су исемен әйтү. Бер әйткән ризыкны кабатламаска. Ярышны кызлар башлап җибәрә. Рәхим итегез.

(Ярышу)

(Командалар авырсынып калса, ярдәмгә җанатарлар килә.)

Алып баручы: Молодцы! Бик күп ризык исемнәрен беләсез икән.

Музыкаль пауза. “Күгәрченнәр гөрләшәләр “ җыры. (Малайлар башкаруында.)

(Җырлау)

Алып баручы: Ә хәзер бирегә командирларны чакырабыз. Рәхим итегез. Барыбыз да беләбез пешекчеләр безнең хатын-кызлар да, ир-атлар да

була. Без командирларыбызны ”Токмач кисү” ярышында сынап карыйбыз.

Менә аларга “киселгән камыр тасмалары“ . Шушы “камыр тасмалары”ннан вак итеп токмачлар кисәргә кирәк. Кемнеке иң вак булыр? Кисәбез һәм тәлинкәләргә тутырып барабыз.

Алар токмач кисә торсыннар, ә без сезнең белән азрак башларны эшләтеп алыйк. Мин сезгә мәкаль, әйтемнәрнең башларын әйтәм, ә сез ахырын әйтеп бетерәсез.

1) Теле барның ..... (юлы бар.)
2) Яхшы сүз ..... (җан азыгы.)
3) Сәламәт тәндә ..... (сәламәт акыл.)
4) Ни чәчсәң ..... (шуны урырсың.)
5) Калган эшкә .....(кар ява.)
6) Эш эшләгән интекмәс ..... (эшләмәгән көн итмәс.)
7) Суга кермичә ..... (йөзәргә өйрәнеп булмый.)
8) Туган илең .....(туган анаң.)
9) Бердә түгел ..... (илдә көч.)
10) Туган илдән .....(туйган юк.)
11) Иленнән аерылган ..... (канаты каерылган.)
12) Батырлык ..... (матурлык.)
13) Батыр яуда ..... (беленер.)
14) Батыр үзе үлсә дә .....(исеме калыр.)
15) Батыр егет ..... (ил күрке.)
16) Үз илең ..... (үз анаң.)
17) Иле юкның ..... (көне юк.)
18) Ирнең данын ..... (ил саклар.)
19) Рәхәт булса да торган җир ..... (сагындыра торган җир.)
20) Ил бар да ..... (ир хур булмас.)
21) Эшле кеше ..... (көчле кеше.)
22) Тир тамган җир ..... (уңдырышлы була.)
23) Ашлаган җир аш бирә ..... (ашламаган таш бирә.)
24) Сабанда сайрашмасаң ..... (ындырда ыңгырашасың.)
25) Күмәк күтәрсә ..... (күлне күчерер.)
26) Кошның матурлыгы – төсенә карап ..... (кешенең матурлыгы эшенә карап.)
27) Һөнәрле үлмәс .....(һөнәрсез көн күрмәс.)
28) Һөнәре бар ..... (үргә йөзәр.)

29) Егет кешегә җитмеш ..... (төрле һөнәр дә аз.)
30) Тырышкан табар ..... (ташка кадак кагар.)
31) Хезмәт кемнеке ..... (икмәк шуныкы.)
32) Батыр ярасыз ..... (булмас.)
33) Дуслык тау ..... (күчерә.)
34) Йөз сум акчаң булганчы ..... (йөз дустың булсачы.)
35) Дусың нинди ..... (кадерең шундый.)
36) Дуслык калаларны ..... (ала.)
37) Ата-ана – алтын ..... (канат.)
38) Бал татлы, бала .....(балдан да татлы.)

- Рәхмәт.
- Командирларның токмачлары киселде. Бик тырыштылар. Молодцы! Бүгенге бәйрәмдә безнең дуслык җиңде. Молодцы! Барыбыз да тырыштык. Рәхмәт барыгызга да.
  Ә хәзер үзебезнең керәшен "Түгәрәк уенын" искә төшереп алыйк әле. Укучылар рәхим итегез.
  (1 баланы түгәрәк эченә алып балалар әйләнәгә басалар һәм бер якка әйләнеп җырлыйлар. Кушымтага уртадагы бала түгәрәктәге 1 баланы биеп ала һәм әйләнәләр. Уртадагы бала түгәрәктәге бала урынына түгәрәккә баса. Уен шулай дәвам итә.)
  (Уйнау)
- Молодцы! Рәхмәт. Безнең бәйрәм ахырына якынлашты. Бәйрәм ахырында үзебезнең керәшен җыруын "Кәвәл авылы көен" искә төшерик әле. Әйдәгез барыбыз бергә җырлыйбыз.
  (Җырлау)
  Алып баручы: Рәхмәт. Шуның белән бәйрәмнең бер өлеше тәмам. Вакыт табып безнең бәйрәмгә килүегез өчен зур рәхмәт. Барыгызны да 23 нче февраль һәм 8 нче март бәйрәмнәре белән котлыйм.
  Илебездә барыбызга да матур, бәрәкәтле тормышта имин булып яшәргә язсын.
  (Мәктәп җитәкчесе сүзе)
- Ә хәзер, әйдәгез "Бәйрәм чәенә" рәхим итегез.